МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2018 г. Казань № под-1556/18

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2015 елның 6 маендагы 5698/15 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 1 октябрендәге 891 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 6 маендагы под-5698/15 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгълүмати технологияләр һәм иминлек бүлегенә (А.А. Кравцов) Министрлык тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында урнаштыруны тәэмин итәргә (http://tatarstan.ru/regulation).»;

Приказ белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибендә:

I бүлектә:

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итү һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына, шул исәптән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү процедурасын билгели.»;

1.5 пунктында «норматив хокукый актны бәяләү» сүзләреннән соң «(норматив хокукый акт проекты)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.6 пунктын өстәргә:

«1.6. Норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза уздыру буенча вәкаләтле зат башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә актка (акт проектына) бәя бирә.»;

III бүлектә:

3.7 пунктында «регистрацияләнә» сүзеннән соң «керү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә"»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Бәяләмә тәкъдим итү характерына ия һәм Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Эшләүче кергән Бәяләмәне карый һәм аны алганнан соң 15 көн эчендә, әлеге Тәртипнең $3.8^1$ пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка мотивлаштырылган җавап җибәрә.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган юридик яисә физик заткы карау нәтиҗәләре буенча, дәлилләнгән җавап җибәрелә (ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат яисә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яисә) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциоген фактор белән килешмәү сәбәпләре чагыла.»;

$3.8^1$ и $3.8^2$ пунктларын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«$3.8^1$. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә каралмау очраклары:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертизасын уздыру экспертлары буларак аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән экспертизалар;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формада булмаган экспертизалар.

$3.8^2$. $3.8^1$ пунктның өченче абзацында күрсәтелгән очракта, эшләүче мондый Бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлү көненнән 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтара.»;

«Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле VI бүлек өстәргә:

«VI. Норматив хокукый актлар проектлары буенча иҗтимагый фикер алышу

4.1. Министрлык эшләнә торган актлар проектлары буенча иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итә.

4.2. Иҗтимагый фикер алышу максатларында актлар проектлары Татарстан Республикасының Рәсми порталында ((http://tatarstan.ru/regulation) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары актлары проектларын аларның коррупциягә каршы бәйсез экспертизасын уздыру һәм җәмәгать тикшерүен үткәрү өчен урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-порталда урнаштырыла (алга таба – Мәгълүмати ресурс)

4.3. Мәгълүмат ресурста иҗтимагый фикер алышу өчен гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы актлар проектлары урнаштырыла.

4.4. Түбәндәге актлар иҗтимагый фикер алышу өчен урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган актлар яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр булган проектлар;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) үз көчләрен югалткан дип тану турында актлар проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән актлар проектларын эшләү өчен бирелгән срок Иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан кимрәк (мәгълүмат ресурсында урнашкан көннән биш эш көненнән кимрәк);

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яисә чыгымнарына йогынты ясый торган актлар проектлары;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы актлар проектлары;

терроризмга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашырганда, шул исәптән террорчылыкны финанслауга каршы чараларны гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен регламентлый торган актлар проектлары;

Татарстан Республикасы законнарына кертелгән үзгәрешләр белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән актлар проектлары;

судлар карарларын, прокурор реакциясе актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында әзерләнгән актлар проектлары;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары һәм дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлар проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында актлар проектлары;

Татарстан Республикасы актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында актлар проектлары.

4.5. Иҗтимагый фикер алышу өчен актлар урнаштырганда проект эшләнгән структур бүлекчә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ясау өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы), шулай ук җәмәгать фикер алышу срогын башлау һәм төгәлләү датасын күрсәтә.

4.6. Әзерләүче билгели торган актлар проектлары буенча иҗтимагый фикер алышуның срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырылган көннән алып биш эш көненнән кимрәк була алмый.

4.7. Проект эшләнгән структур бүлекчә тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча акт проектын эшләп бетерү турында карар кабул ителгән очракта, эшләнеп беткән акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу өчен урнаштырыла.

4.8. Норматив хокукый актлар проектларын Мәгълүмат ресурсына урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 30 көн эчендә, эшләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү барышында ачыкланган коррупциоген факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып кергән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүмат урнаштыра.»;

Тәртипне түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта белән тулыландырырга:

« Министрлык тарафыннан эшләнә торган хокукый актлар
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнүче норматив хокукый актлар һәм норматив актлар проектлары коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә
4 нче кушымта

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча җыелма мәгълүмат

____________________________________________________________

(норматив хокукый акт төре)

____________________________________________________________

(норматив хокукый акт проектының исеме)

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

| № п/п | Эксперт (Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта )/ аккредитация турында күрсәтмә реквизиты) | Ачыкланган коррупциоген фактор | Эшләүченең комментарийлары |
| --- | --- | --- | --- |

Иҗтимагый фикер алышу

| № п/п | Фикер алышуда катнашучы (Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта)/ электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Эшләүченең комментарийлары |
| --- | --- | --- | --- |

Кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны
Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны
Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны
Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов